| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |

**Карар** **Решение**

№ 7-34 от «23» июля 2019 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 17.12.2018 ел, 6-30 санлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә күздә тотылган хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекнең эйләнә- тирәлеккә йогынтысын бәяләү буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә” үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Казан районара табигатьне саклау прокуратурасының 01.03.2019 ел, 02-06- 2019/3 санлы, протестын карап, Россия Дәүләт экология комитетының “Россия Федерациясендә әйләнә- тирә мохиткә йогынтыны бәяләү турындагы Нигезләмәне раслау турында” 2000 елның 16 маендагы 372 нче санлы боерыгы, “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 17.12.2018 ел, 6-30 санлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә күздә тотылган хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекнең эйләнә- тирәлеккә йогынтысын бәяләү буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә” түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2.6.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«- иҗтимагый фикер алышуны оештыру өчен җаваплы орган».

1.2. Нигезләмәләнең 2.6 пунктын түбәндәге эчтәлекле 2.6.1 һәм 2.6.1.2 пунктчалары белән тулыландырырга:

“2.6.1.1. әйләнә-тирәлеккә йогынтыны бәяләү процессында катнашучыларны, шул исәптән кызыксынучы җәмәгатьчелекне билгеләү максатында өстәмә консультацияләр үткәрә.”

“2.6.1.2. ниятләнгән инвестицион эшчәнлек өчен Нигезләмәдә күрсәтелгән әйләнә-тирәлеккә йогынтыны бәяләү этаплары Дәүләти экологик экспертизага тәкъдим ителә торган хуҗалык һәм башка төр эшчәнлек буенча документлар әзерләүнең барлык стадияләрендә дә үткәрелә.”

000065

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Советының Җирле үзидарә, аграр сәясәт, җирдән файдалану һәм экология буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов